Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авыл җирлегенең Борискино авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 ноябрь 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең Борискино авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 23 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең Борискино авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең Борискино авылында 2019 елның 23 ноябрендә узган халык җыенын үткәрелгән дип таныргa, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Борискино авыл җирлегенең Борискино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Борискино авылы суүткәргеч челтәрләрен норматив хәлгә китерү , смета төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү ?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Борискино авылы, Үзәк урам , 61 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Борискино авыл җирлеге башлыгы Җ.С.Илалов